КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2019 ел, 7 март г.Казань № 163

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2004 ел, 16 апрель, 184 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2004 ел, 30 декабрь, 586 нчы; 2006 ел, 6 февраль, 43 нче; 2006 ел, 3 апрель, 146 нчы; 2006 ел, 1 декабрь, 585 нче; 2007 ел, 7 ноябрь, 607 нче; 2007 ел, 26 декабрь, 744 нче; 2009 ел, 14 гыйнвар, 10/1 нче; 2009 ел, 30 гыйнвар, 45 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 8 июль, 472 нче; 2015 ел, 19 март, 165 нче; 2015 ел, 25 ноябрь, 890 нчы; 2016 ел, 9 август, 549 нчы; 2017 ел, 26 май, 307 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибендә:

1.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Ташламалы шартларда юлламалар белән гаиләләренең җан башына уртача керемнәре Татарстан Республикасы буенча халыкның җан башына яшәү минимумының 500 процентыннан артмаган һәм мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә шифаханә-курорт дәвалавына хокуклары булмаган Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль белем бирү оешмалары, Татарстан

Республикасының дәүләт һәм муниципаль медицина оешмалары, Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль мәдәният оешмалары, Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт һәм муниципаль оешмалары, яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре һәм Татарстан Республикасының физик культура һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре (алга таба – хезмәткәрләр) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Авыруларны медицина күрсәткечләре нигезендә сайлап алу һәм шифаханә-курорт дәвалавына җибәрү тәртибе турында» 2004 ел, 22 ноябрь, 256 нчы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында кулланыла торган медицина документларының унификацияләнгән формаларын һәм аларны тутыру тәртипләрен раслау турында» 2014 ел, 15 декабрь, 834 нче «н» боерыгы белән расланган 070/у формасы буенча бирелә торган белешмә кәгазе (алга таба – 070/у формасы буенча юллама алу өчен белешмә кәгазе) белән расланган медицина күрсәткечләре булган шартларда тәэмин ителә.»;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Территориаль социаль яклау органы хезмәткәрне шифаханә-курорт юлламасын алуга исәпкә кую турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә ала:

вәкаләтле оешмалардан гариза бирүченең гаилә составы турында мәгълүматлар;

Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турында мәгълүматлар;

күчемсез мөлкәт турында мәгълүматлар;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре турында мәгълүматлар.

Мәгълүмати хезмәттәшлек гамәлгә ашырылганнан соң шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында мәгълүматлар ала.

Хезмәткәрләр үз теләге белән бу пунктның икенче – бишенче абзацларында күрсәтелгән мәгълүматлары булган документларны гариза белән бергә һөнәр берлеге оешмасына (территориаль социаль яклау органына) тапшырырга хокуклы.

Территориаль социаль яклау органы бу Тәртипнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән һәм тапшырылган документлар һәм бу пунктның икенче – бишенче абзацларында күрсәтелгән мәгълүматлар нигезендә кирәкле барлык документлар белән бергә гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә хезмәткәрне юллама алуга исәпкә кую турында яки аны бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр итеп, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша) тиешле карар турында хезмәткәркә хәбәр итә.»;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Территориаль социаль яклау органының хезмәткәрне юллама алуга исәпкә куюдан баш тартуы өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

хезмәткәр гаиләсенең җан башына уртача кереме күләме Татарстан Республикасы буенча халыкның җан башына яшәү минимумы күләме 500 проценттан артып китү;

хезмәткәрнең мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән артып киткән булу.»;

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Территориаль социаль яклау органы юлламалар кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә хезмәткәргә юллама бүлеп бирелү һәм эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көн эчендә түбәндәге документларны (гамәли вакытлары чыккан очракта) яңартырга кирәк булу турында хәбәр итә:

юллама алу өчен 070/у формасы буенча белешмә кәгазен;

юллама бирү турында хәбәр ителгән ай алдыннан килгән соңгы өч календарь ае өчен гаиләнең һәр әгъзасы керемнәрен раслый торган документлар.

Территориаль социаль яклау органы ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү системасыннан файдаланып, электрон рәвештә вәкаләтле оешмадан түбәндәге мәгълүматларны ала:

вәкаләтле оешмалардан гариза бирүченең гаилә составы турында мәгълүматлар;

гариза бирүченең эш урынын раслый торган белешмә кәгазен.

күчемсез мөлкәт булу турында мәгълүматлар;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булу турында мәгълүматлар.

Мәгълүмати хезмәттәшлек гамәлгә ашырылганнан соң шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында мәгълүматлар ала.

Хезмәткәрләр үз теләге буенча территориаль социаль яклау органына гариза белән бергә бу пунктның бишенче – сигезенче абзацларында күрсәтелгән документларны тапшырырга хокуклы.

Территориаль социаль яклау органы яңартылган мәгълүматларны хезмәткәр тапшырган һәм территориаль социаль яклау органы алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә хезмәткәргә юллама бирү турында яки аны бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча язма рәвештә, электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга СМС-хәбәр итеп, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша) тиешле карар турында хезмәткәркә хәбәр итә.»;

3.4 пунктта:

беренче абзацта татарча текстта «бирүдән баш тарту» сүзләре үзгәрешсез кала;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«хезмәткәрнең мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән артып киткән булу.»;

3.5 пунктта татарча текстта «бирү турында карар» сүзләре үзгәрешсез кала.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 ел, 17 декабрь, 542 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 22 гыйнвар, 22 нче; 2005 ел, 30 май, 239 нчы; 2006 ел, 2 октябрь, 490 нчы; 2007 ел, 6 апрель, 123 нче; 2008 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2010 ел, 29 ноябрь, 956 нчы; 2011 ел, 21 июнь, 496 нчы; 2011 ел, 6 декабрь, 1001 нче; 2012 ел, 13 апрель, 304 нче; 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 8 февраль, 80 нче; 2014 ел, 5 декабрь, 947 нче; 2015 ел, 15 апрель, 254 нче, 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче; 2016 ел, 10 сентябрь, 625 нче; 2016 ел, 20 декабрь, 959 нчы; 2017 ел, 10 май, 268 нче; 2017 ел, 28 август, 604 нче; 2017 ел, 27 октябрь, 812 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1228 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнарга (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар), 2018 елның 31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнар белән күздә тотылган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән Татарстан Республикасында яшәүче гражданнарга (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар), мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре күләме 20 000 сумнан артмаган һәм мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә социаль ярдәм чараларына хокуклары булмаган пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү бирелә, 2019 елда аның күләме 486 сум тәшкил итә;

пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнарга (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар), 2018 елның 31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнар белән күздә тотылган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән Татарстан Республикасында яшәүче гражданнарга (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар), мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре күләме 20 000,01 сумнан 25 000 сумга кадәр (25 000 сумны кертеп) тәшкил иткән һәм мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм

күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган, Россия Федерациясе һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә социаль ярдәм чараларына хокуклары булмаган пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү бирелә, 2019 елда аның күләме 180 сум тәшкил итә;»;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Бу карарның 2 нче пунктындагы икенче һәм өченче абзацларда күрсәтелгән ялгыз яшәүче гражданнарның мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсен бәяләгәндә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымтаның «а» пунктчасы нигезендә 40 квадрат метр урынына 80 квадрат метр кулланыла.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктта:

сигезенче абзацта «өс киемнәре, аяк киемнәре» сүзләрен «өс киемнәре, аяк киемнәре комплекты» сүзләренә алыштырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төп һөнәри белем бирү программалары буенча һәм (яки) эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга өс киемнәре, аяк киемнәре комплекты һәм йомшак инвентарь сатып алуга еллык пособие (алга таба – өс киемнәре, аяк киемнәре комплекты һәм йомшак инвентарь сатып алуга еллык пособие);»;

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төп һөнәри белем бирү программалары буенча һәм (яки) эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга тукландуга еллык пособие (алга таба – тукландуга еллык пособие);»;

3.1 пунктка «һәм мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган» сүзләрен өстәргә;

3.11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«күчемсез мөлкәт булу турында мәгълүматлар;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булу турында мәгълүматлар.»;

6 бүлекнең исемендә «өс киемнәре, аяк киемнәре» сүзләрен «өс киемнәре, аяк киемнәре комплекты» сүзләренә алыштырырга;

6.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.2. Дәреслекләр һәм язу кирәк-яраклары сатып алуга еллык пособие төп һөнәри белем бирү программалары буенча һәм (яки) эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга (шул исәптән алар 23 яшькә һәм аннан да күбрәк яшькә җиткәндә) билгеләнә һәм түләнә.

Өс киемнәре, аяк киемнәре комплекты һәм йомшак инвентарь сатып алуга еллык пособие, туклануга еллык пособие төп һөнәри белем бирү программалары буенча һәм (яки) эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерләү программалары буенча Татарстан Республикасы бюджеты яки җирле бюджетлар акчасы исәбеннән белем алучы ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасындагы затларга һәм уку чорында ата-анасын яки бердәнбер атасын (анасын) югалткан затларга (шул исәптән алар 23 яшькә һәм аннан да күбрәк яшькә җиткәндә) билгеләнә һәм түләнә.

Өс киемнәре, аяк киемнәре комплекты һәм йомшак инвентарь сатып алуга еллык пособие, туклануга еллык пособие опекага (попечительлеккә), тәрбиягә бала алучы гаиләләргә тапшырылган һәм аларны тәрбияләү өчен опекунга (попечительгә) акча түләнгән ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга билгеләнми һәм түләнми.»;

6.3, 6.5, 6.8, 6.10, 6.11, 6.12, 6.15 пунктларда «өс киемнәре, аяк киемнәре» сүзләрен «өс киемнәре, аяк киемнәре комплекты» сүзләренә алыштырырга;

9.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.1. Транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнарга (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар), 2018 елның 31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнар белән күздә тотылган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 60 һәм 55 яшькә җитмәгән Татарстан Республикасында яшәүче гражданнарга (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар), мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре күләме 25 000 сумнан артмаган һәм мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә социаль ярдәм чараларына хокуклары булмаган пенсионерлар яки аларның законлы вәкилләре яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар (алга таба – гариза бирүчеләр) Үзәкнең үзләре яшәгән урындагы бүлегенә түбәндәгеләрне кертә:»;

9.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.2. Үзәк бүлеге вәкаләтле оешмалардан ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә түбәндәге мәгълүматларны соратып ала:

транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында;

күчемсез мөлкәт булу турында;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булу турында.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 11 февраль, 105 нче; 2014 ел, 2 сентябрь, 635 нче; 2015 ел, 19 март, 165 нче; 2017 ел, 26 май, 307 нче; 2018 ел, 12 декабрь, 1117 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибендә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Ташламалы шартларда юлламалар белән пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, башка нигезләр буенча пенсия алучы яки эш (хезмәт) өчен гомерлек акчалата керем алучы пенсионерлар «Иминият пенсияләре турында» Федераль законның 8 статьясындагы беренче өлеш нигезендә картлык буенча иминият пенсиясенә хокук бирүче яшькә җиткәч, Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, гаиләсенең җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән пенсионерның яшәү минимумы күләменең 400 процентыннан артмаган һәм мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә шифаханә-курорт дәвалавына хокуклары булмаган 60 һәм 55 яшькә җиткән гражданнар (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Авыруларны медицина күрсәткечләре нигезендә сайлап алу һәм шифаханә-курорт дәвалавына җибәрү тәртибе турында» 2004 ел, 22 ноябрь, 256 нчы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында кулланыла торган медицина документларының унификацияләнгән формаларын һәм аларны тутыру тәртипләрен раслау турында» 2014 ел, 15 декабрь, 834 нче «н» боерыгы белән расланган 070/у формасы буенча бирелә торган белешмә кәгазе (алга таба – 070/у формасы буенча шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен белешмә кәгазе) белән расланган медицина күрсәткечләре булган шартларда тәэмин ителә.»;

2.2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2.1. Гражданны шифаханә-курорт юлламасын алуга исәпкә кую турында карар кабул итү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматларны ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә ала:

вәкаләтле оешмалардан «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында мәгълүматлар;

вәкаләтле оешмалардан гариза бирүченең гаилә составы турында мәгълүматлар;

Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турында мәгълүматлар;

күчемсез мөлкәт булу турында мәгълүматлар;

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булу турында мәгълүматлар.

Мәгълүмати хезмәттәшлек гамәлгә ашырылганнан соң шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында мәгълүматлар ала.

Граждан үз теләге белән бу пунктның икенче – алтынчы абзацларында күрсәтелгән мәгълүматлары булган документларны гариза белән бергә территориаль социаль яклау органына тапшырырга хокуклы.»;

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Гражданны юллама алуга исәпкә куюдан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

граждан гаиләсенең җан башына уртача кереме күләме Татарстан Республикасында билгеләнгән пенсионерның яшәү минимумы күләменнән 400 процентка артып китү;

гражданның мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән артып киткән булу.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Территориаль социаль яклау органы:

шифаханә дәвалавы юнәлеше буенча юлламалар кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 3 көн эчендә гражданга шифаханә дәвалавы юнәлеше буенча юллама керү турындагы һәм эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көн эчендә бу Тәртипнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән документларны (гамәли вакытлары чыккан очракта) яңартырга кирәк булу хакындагы мәгълүматны чират нигезендә хәбәр итә:

ведомствоара сораулар нигезендә, шул исәптән, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү системасыннан файдаланып, электрон рәвештә бу Тәртипнең 2.2.1 нче пунктындагы икенче – алтынчы абзацларда күрсәтелгән мәгълүматларны ала;

мәгълүмати хезмәттәшлек гамәлгә ашырылганнан соң шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында мәгълүматлар ала;

яңартылган документларны һәм мәгълүматларны граждан тапшырган һәм территориаль социаль яклау органы алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган

3 көн эчендә юллама бирү турында яки аны бирүдән баш тарту хакында карар кабул итә һәм почта аша яки гражданның теләге буенча гаризада күрсәтелгән ысулларның берсе ярдәмендә (телефон, sms-хәбәр, электрон почта аша) кабул ителгән карар турында гражданга хәбәр итә.

Граждан үз теләге буенча территориаль социаль яклау органына бу Тәртипнең 2.2.1 нче пунктындагы икенче – алтынчы абзацларда күрсәтелгән мәгълүматлары булган документларны тапшырырга хокуклы.

Тәртипнең 3 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 3.5 пункт өстәргә:

«3.5. Гражданга юллама бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

бу Тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау яки аларның тулы булмаган пакетын тапшыру;

гамәли вакыты чыккан документлар тапшыру;

граждан гаиләсенең җан башына уртача кереме күләме Татарстан Республикасында билгеләнгән пенсионерның яшәү минимумы күләменнән 400 процентка артып китү;

гражданның мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсе «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законына теркәлгән кушымта белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеше дәрәҗәсеннән артып киткән булу;

граждан Татарстан Республикасы чигеннән читкә чыгу;

граждан Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә шифаханә-курорт дәвалавына хокуклы халык категорияләренә карау.».

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына социаль ярдәм чаралары күрсәтү өчен кирәкле мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе турында мәгълүматлар алу өлешендә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне тормышка ашыруны тәэмин итәргә.

5. Бу карар 2019 елның 1 апреленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин